ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24 июль 2018 ел № 4158

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияләрне үтәүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 3 ноябрендәге 306-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2018 елның 27 мартындагы 1631 нче карары белән (Башкарма комитетның 2018 елның 10 июлендәге 3844 нче карары редакциясендә) расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияләрне үтәүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Муниципаль функцияне үтәү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

- Россия Федерациясе Конституциясе («Российская газета», №237, 25.12.1993);

- Россия Федерациясе Торак кодексы, 29.12.2004 ел, №188-ФЗ («Собрание законодательства РФ», 03.01.2005, №1 (1 бүлек), ст. 14; «Российская газета», 12.01.2005, №1; «Парламентская газета», 15.01.2005, №7-8) (алга таба – РФ Торак кодексы);

- Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы 30.12.2001, №195-ФЗ («Российская газета», №256, 31.12.2001; «Парламентская газета», №2-5, 05.01.2002; «Собрание законодательства РФ», 07.01.2002, №1 (1 бүлек), ст. 1) (алга таба – РФ Административ хокук бозулар турында кодексы);

- «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон («Собрание законодательства РФ», 06.10.2003, №40, ст. 3822; «Парламентская газета», №186, 08.10.2003; «Российская газета», №202, 08.10.2003) (алга таба – 131-ФЗ санлы Федераль закон);

- «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ санлы Федераль закон («Российская газета», №266, 30.12.2008; «Собрание законодательства РФ», 29.12.2008, №52 (1 бүлек), ст. 6249; «Парламентская газета», № 90, 31.12.2008) (алга таба – 294-ФЗ санлы Федераль закон);

- «Россия Федерациясендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ санлы Федераль закон («Российская газета», №95, 05.05.2006, «Собрание законодательства РФ», 08.05.2006, №19, ст. 2060, «Парламентская газета», №70-71, 11.05.2006);

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләрне планлы рәвештә тикшерүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 30 июнендәге 489 нчы карары («Собрание законодательства РФ», 12.07.2010, №28, ст. 3706) (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 489 нчы Карары);

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан документларны һәм (яки) мәгълүматны сорап, шул исәптән электрон рәвештә, әлеге документлар һәм (яки) мәгълүмат белән эш итүче башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына яисә дәүләт органнары яисә җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмаларга ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында запрослар җибәрү һәм аларны түләүсез нигездә алу турында» 2016 елның 18 апрелендәге 323 нче карары («Собрание законодательства РФ», 25.04.2016, №17, ст. 2418);

- Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру турында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 нче Приказы («Российская газета», №85, 14.05.2009) (алга таба – РФ Икътисадый үсеш министрлыгының №141 нче приказы);

- Татарстан Республикасының «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ санлы Законы («Ватаным Татарстан», №201-203, 19.10.2011; «Республика Татарстан», №201, 21.10.2011; Татарстан Дәүләт Советы җыелма басмасы, №10 (I бүлек), октябрь 2011) (алга таба – №72-ТРЗ санлы ТР Законы);

- «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге Вәкиллекле органының 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы («Челнинские известия», №235-237, 10.12.2005, «Челнинские известия»,

№249-250, 30.12.2005) (алга таба – шәһәр Уставы).

2) 4 бүлекне түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

«Муниципаль торак контроле органы тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән исемлеккә кертелгән түбәндәге документларны һәм (яки) мәгълүматны, шул исәптән электрон рәвештә, әлеге документлар һәм (яки) мәгълүмат белән эш итүче дәүләт органнарыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән срокларда һәм тәртиптә сорый һәм аларны түләүсез нигездә ала:

- Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан мәгълүматлар;

- Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан мәгълүматлар;

- күчемсез милек объекты турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә.

Салым яки закон буенча саклана торган башка серне үз эченә алган мәгълүматлардан торган документларны һәм (яки) мәгълүматны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында соратып алу, тиешле мәгълүматларны тикшерү юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәү фактын ачыклау зарурлыгына бәйле булу шарты белән һәм күрсәтелгән мәгълүматларны бирү федераль законнарда каралган очракта рөхсәт ителә.

Документларны һәм (яки) мәгълүматны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшыру, аларны ачып салу, шул исәптән федераль законнарда каралган очракларда алар белән таныштыру, дәүләт һәм закон нигезендә саклана торган башка сер турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.»;

3) 5.1.1.4 пунктны түбәндәге эчтәлектәге тугызынчы һәм унынчы абзацлар белән тулыландырырга:

«Җаваплы башкаручы документлар һәм (яки) мәгълүмат белән эш итүче дәүләт органына ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында документлар һәм (яки) мәгълүмат бирү турында запрос җибәрә.

Үтәү срогы: тикшерү үткәрү турында боерык имзаланган көннән башлап бер эш көне эчендә.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Р.Ә. Абдуллин